ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләре киңәшмәсен чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының беренче утырышында карауга чыгарыла торган мәсьәләләрне алдан карап фикер алышу өчен 2024 елның 18 сентябрендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кече залында җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләре киңәшмәсен чакырырга.

2. Сәяси партияләрдән җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлыгына кандидатларның һәр республика исемлеге буенча сайланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләрен сайлауларны 2024 елның 17 сентябреннән дә соңга калмыйча күрсәтелгән депутатлар җыелышларында үткәрергә.

3. Бермандатлы сайлау округларыннан сайланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләрен сайлауларны 2024 елның 17 сентябреннән дә соңга калмыйча 2024 елның 11 июлендәге 2597-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләре киңәшмәсе турындагы нигезләмәнең 2.4 пункты нигезендә күрсәтелгән депутатларның территориаль җыелышларында үткәрергә.

4. Бермандатлы сайлау округлары буенча сайланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының территориаль җыелышларын әзерләүне оештыруны һәм үткәрүне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының түбәндәге әгъзаларына йөкләргә:

1) 1 – 16 нчы бермандатлы сайлау округлары буенча 2024 елның 17 сентябрендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 219 нчы кабинетында – Ф.Х. Мөхәммәтшинга;

2) 17 – 23, 37, 42 нче бермандатлы сайлау округлары буенча 2024 елның 16 сентябрендә 13 сәгатьтә Чаллы шәһәре Мэриясе бинасында – Л.Н. Мавринага;

3) 24 – 26, 34, 35, 38, 43, 44 нче бермандатлы сайлау округлары буенча 2024 елның 16 сентябрендә 13 сәгатьтә Түбән Кама муниципаль районы Советы бинасында – Е.И. Кузьмичевага;

4) 27 – 29, 32, 33, 36, 39, 40 нчы бермандатлы сайлау округлары буенча 2024 елның 16 сентябрендә 12 сәгатьтә Әлмәт муниципаль районы Советы бинасында – Л.А. Якунинга;

5) 30, 31, 41, 45 нче бермандатлы сайлау округлары буенча 2024 елның 17 сентябрендә 10 сәгатьтә Зеленодольск муниципаль районы Советы бинасында – Ю.З. Камалтыновка;

6) 46 – 50 нче бермандатлы сайлау округлары буенча 2024 елның 17 сентябрендә 10 сәгатьтә Лаеш муниципаль районы Советы бинасында – М.Г. Әхмәтовка.

5. Депутатлыкка кандидатларның республика исемлекләре буенча сайланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының җыелышларын әзерләүне һәм үткәрүне координацияләүне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының түбәндәге әгъзаларына йөкләргә:

1) «ЕДИНАЯ РОССИЯ» Бөтенроссия сәяси партиясеннән депутатлыкка кандидатларның республика исемлеге буенча – Ю.З. Камалтыновка;

2) «Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» сәяси партиясеннән депутатлыкка кандидатларның республика исемлеге буенча – Х.Г. Миргалимовка.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 13 сентябре
№ 2611-VI ДС